ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

« 10 » март 2025 ел Яр Чаллы ш. № 624

Башкарма комитетның 2023 елның 28 декабрендәге 4575 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»нә үзгәрешләр кертү турында

Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны йөртү белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Тукай муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшкуарларга, шулай ук товар җитештерүче, эш һәм хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 887 санлы карары, Тукай муниципаль берәмлеге уставы, Башкарма комитет Җитәкчесенең 2013 елның 22 маендагы «Административ регламентларны раслау турында» 2670 санлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 28 декабрендәге 4575 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында,

пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтага комиссиянең түбәндәге әгъзаларын өстәргә:

- Нәҗмиев Камил Рим улын- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе

2. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълумат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үталешен контрольда тотуны үз өстемдә калдырам

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 елның 10 03 624 номерлы карарына 2 кушымта

Комиссия составы

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | |
| Нәҗмиев К.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| Комиссия рәисе урынбасары | |
| Хәбибуллин А.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Комиссия әгъзалары | |
| Галимова Г.Ә. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары |
| Заһретдинов Ф.С. | Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Шәяхмәтова Р.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Салихова Г.Ф. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Комиссия секретаре | |
| Мадярова Д.Ә. | төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече |